**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с. Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17 йорт, Актаныш ав., 423740

Тел. (85552) 3-44-22, факс (85552) 3-44-14, E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

__________ ПР-36 26.02.2024 № _____

Махсус хәрби операциядә катнашучы Актаныш муниципаль районы гражданнарының гаиләләренә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә ярдәм чаралары турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 273 номерлы Федераль законнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның һәм махсус хәрби операциядә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләренә ярдәм буенча өстәмә чаралар турында» 2022 елның 20 октябрендәге 1122 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2022 елның 09 ноябрендәге 1903/22 номерлы боерыгы белән «Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнары гаиләләренә ярдәм итүнең өстәмә чаралары турында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Уставы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның гаиләләрен һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнарның гаиләләрен мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирүне гамәлгә ашыручы Актаныш муниципаль районы мәгариф оешмаларында балаларны карау, тәрбияләү һәм ашату өчен ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләүдән азат итәргә.

2. Мәктәпкәчә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы муниципаль белем бирү оешмасына чираттан тыш кабул итү хокукы бирү;

3. Муниципаль мәгариф оешмаларында 1-11 нче сыйныфларда белем алучыларны ике тапкыр түләүсез кайнар ризык (1 нче иртәнге, 2 нче иртәнге аш) белән тәэмин итәргә;

4. Гомуми белем бирү оешмаларында озайтылган көн төркеменә йөрүче балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итәргә;

5. Өстәмә белем бирү учреждениеләрендә һәм түгәрәкләрендә, һәм гомуми белем бирү оешмалары базасында эшләүче өстәмә белем бирү секцияләрендә түгәрәкләргә һәм секцияләргә бушлай йөртүне тәэмин итәргә.

6. Җәмәгать транспортына бушлай йөрүне тәэмин итәргә. Ташлама 8 яшьтән 18 яшькә кадәрге балаларга кагыла. Бушлай йөрү ата-аналар яки законлы вәкилләр гаризасы буенча кораллы көчләргә мобилизацияләнгән Россия Федерациясе гражданнары белән туганлыкны раслаучы документлар нигезендә бирелә.

Бушлай йөрү өчен ташлама шәһәрара автобус маршрутларына кагылмый.

7. Югарыда күрсәтелгән ташламалар махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләрендә яшәүче башка никахтан туган балаларга да, махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә дә, туендыручысын югалткан очракта да кагыла.

8. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Мәгариф идарәсе» МКУ:

8.1. Хәрби комиссариатның белем бирү оешмасында укучы тәрбияләнүченең ата-анасын (законлы вәкилен) чакыру турында белешмәсе нигезендә, 1-6 пунктларында күрсәтелгән ташламалар бирергә.

8.2. Махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар кайтарылган очракта ташламаның гамәлдә булуын туктатуны контрольдә тоту максатыннан, хәрби комиссариат белән үзара хезмәттәшлекне күздә тотарга.

9. Актаныш муниципаль районының финанс-бюджет палатасына Актаныш муниципаль районының мәгариф оешмаларында махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнар гаиләләреннән укучы тәрбияләнүчеләргә һәм махсус хәрби операциядә катнашу нәтиҗәсендә һәлак булган (үлгән) гражданнар гаиләләренә ярдәм итү, карап тоту һәм туклану чараларын финанслауны тәэмин итәргә.

10. «Актаныш муниципаль районының мәктәпкәчә, төп һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында күзәтү, карау һәм туклану өчен түләүдән махсус хәрби операциядә катнашучы гражданнарның балаларын азат итү турында» 2023 елның 13 ноябрендәге ПР-242 номерлы карарын, 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

11. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2024 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

12. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.М. Әнвәровага йөкләргә.

Җитәкче Р.А.Ильясов